РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин ур. 15.

РЕШЕНИЕ КАРАР

20 май 2020 ел №12

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара штп. муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүе турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара штп. муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирүе турындагы Кукмара посёлок Советының 2014 елның 25 ноябрендәге 35 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертү турында:

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы нигезендә Кукмара шәһәре Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара штп. муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирүе турында, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара штп. муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирүе турындагы Кукмара посёлок Советының 2014 елның 25 ноябрендәге 35 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) карар һәм нигезләмәләрнең исемендә һәм бөтен тексты буенча «Кукмара штп.» сүзләрен «Кукмара ш.» сүзләренә алмаштырырга;

2) 4 пунктта «ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, шулай ук махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга

Кукмара шәһәре Мэры С. Д. Димитриев

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ГОРОД КУКМОР КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ * ТР КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУКМАРА ШӘҺӘРЕ БЕРӘМЛЕГЕ *
Совет города Кукмор
ИНН 1623001484
Кукмара шәһәре Советы